| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

24.11.2021 Казан ш. № 360-78/кс-2021

«ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2020 №252-85/кс-2020 карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, эчә торган суга, су агызуга 2022-2025 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай кеременә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021-2025 елларга «Эко» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләү турында» 20.11.2020 № 252-85/кс-2020 карарына 1 нче кушымтага, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.11.2020 № 252-85/кс-2020 карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
24.11.2021 № 360-78/кс-2021
карары редакциясендә) 1 нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» ҖЧҖ өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2021-2025 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | Питрәч муниципаль районы | | | |
| 1 | «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» ҖЧҖ* | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 25,15 | 25,98 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 26,19 | 27,01 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 26,19 | 27,01 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 27,19 | 29,22 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 25,31 | 28,66 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 25,31 | 28,66 |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 25,31 | 28,66 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 26,02 | 29,78 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 26,02 | 29,78 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 26,04 | 29,82 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге